ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис, Верхнеуслонский район, Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

08.05.2018 | г. Иннополис | № 28

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге автомобиль юллары буйлап 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 73 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган тантаналы чаралар уздыру чорында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

1941-1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 73 еллыгын бәйрәм итүгә, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә вакытлыча туктату тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы карары нигезендә чаралар әзерләү һәм уздыру максатларында Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елның 9 маенда Иннополис шәһәрендә транспорт чараларының барлык төрләренең хәрәкәтен 13:00 дән алып йөреш тәмамланганчыга кадәр түбәндәге участокларда чикләргә:

- Спорт ур. (боҗра);
- Уң полоса буенча Университет урамы (студентлар тулай торакларыннан) - Квант бульвары;
- Квант бульвары (Университет урамыннан) - 2 нче кварталара юл;
- 2 нче кварталара юл, 1 нче кварталара юл (спорт урамы киселешендә).

2. Иннополис шәһәре Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеге начальнигына:

2.1. 2018 елның 8 маенда 12:00 гә кадәр күрсәтелгән автомобиль юлларын карап тотучы оешмалар хәрәкәтен вакытлыча чикләү, “Югары Ослан” Россия ЭЭМның районара бүлеге, Иннополис шәһәре халкы һәм кунакларына хәбәр итәргә.

2.2. «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең автомобиль юллары буенча транспорт чараларының 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 73 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган тантаналы чаралар уздыру чорында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең автомобиль юллары буенча хәрәкәтен вакытлыча чикләүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы карары нигезендә оештырырга.

3. Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлеге начальнигына полиция полковнигы О.Е.Хохоринга транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү гамәлдә булган чорда юл хәрәкәте иминлеген саклауны тикшереп торуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. 7 көн эчендә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иннополис шәһәре Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеге башлыгы А.Ю.Нижегородовага йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Шагалеев